**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКЪЕГЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**2023 ел 18 нче гыйнвар** **№104**

2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Акъегет авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Акъегет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәвен билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча бастырып чыгарырга: Акъегет авылы , Центральная урамы, 4 йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасы), Акъегет авылы, Центральная урамы, 6 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы)., шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Акъегет авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Акъегет авыл җирлеге башлыгы,Совет рәисе А. В. Хәйруллина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1021606753761 СОВЕТ АКЗИГИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКЪЕГЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1648001197 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ